**СОВЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Высокогорский район РТ,
с.Высокая Гора, ул.Юбилейная, д. 1 А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422700, ТР Биектау районы,
Биекта уавылы, Юбилей ур., 1 А

Тел./факс: +7(84365) 74-779,74-778 e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**26 март, 2022 ел** **№ 190**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты структурасын тәртипкә салу, муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы муниципаль район

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларны, сайланулы вазыйфаи затларны, муниципаль хезмәткәрләрне, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, шулай ук «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләрен премияләү турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 04 июлендәге 389 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең җирле үзидарәсе муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 апрелендәге 346 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы

Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Муниципаль хезмәт – әйдәп баручы белгеч вазыйфасын дүрт берәмлек күләмендә 13453 сум күләмендәге вазыйфаи оклад белән гамәлгә кертергә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитетына штат расписаниесенә үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 01 апреленнән үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
Биектау авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары М.Н. Касюков